



# КӨМЕШ КЫҢГЫРАУ

**№3** **НОЯБРЬ, 2014 нче ел**

**Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа төп гомуми белем бирү мәктәбе**

## Уку елының I чиреге тәмамланды

**Мәктәптәге (Кече Кибәхуҗа төп һәм Олы Кибәхуҗа башлангыч мәктәпләре) 44 укучының 20 се (48%) I чирекне "4" һәм "5" билгеләренә тәмамлады.**

**II сыйныф укучылары Рахматуллина Диана белән Мөлекова Динә гел "5" билгеләренә укыйлар.**

**"4" һәм "5" билгеләренә түбәндәге укучылар өлгерә:**

**II сыйныфтан**

**Закиров Илнур,Нәбиуллин Рөстәм.**

**III сыйныфтан**

**Ганина Юлия, Мөхәмәдиева Сиренә, Вәлиева Резеда,Миннебаев Илназ,Саидов Бахтовар.**

**IV сыйныфтан Гараев Гадел.**

**V сыйныфтан Әхмәтҗанова Алия, Шәяхмәтова Сөмбел.**

**VI сыйныфтан Әскарова Әдилә, Рахматуллина Энже,Даутова Гөлшат.**

**VII сыйныфтан Саидова Муниса**

**VIII сыйныфтан**

**Гыйлметдинова Ләйлә, Ибраһимов Рүзәл**

**IX сыйныфтан**

**Даутова Дилбәр,Сафиуллина Илүзә**

**УҢЫШЛАРЫГЫЗ БЕЛӘН КОТЛЫЙБЫЗ!**




## Халык- без ул!

4 ноябрь көнне Россия халыклар бердәмлеге көнен билгеләп үтә. Бу бәйрәм - чагыштырмача яшь. Күпләр Минин һәм Пожарский исемнәренең халыклар бердәмлеге белән бәйләнеше турында аз гына ишетеп белә иде. Хәзер исә Мәскәүнең поляклардан азат ителү тарихы һәркемгә мәгълүм.

Иң мөһиме- халыклар бердәмлегенең бүгенге көндә никадәр кирәклегенә төшенү.Бердәмлек- ил куәте, икътисади үсеш, илдәге сәяси хәл белән янәшә йөри. Бу төшенчәләр җәмгыятьнең нигезен тәшкил итә. Без авыр вакытта бер- беребезгә ярдәм итәргә, бердәм булырга тиеш. Барыгызны да бәйрәм белән котлыйбыз! Илебезне үстерүдә армый- талмый хезмәт итүегезне телибез.

# ТӨП ДӘҮЛӘТ ИМТИХАННАРЫНА ӘЗЕРЛЕК



9 нчы сыйныф укучыларын төп дәүләт имтиханына әзерләүнең сыйфатын яхшырту буенча чаралар дәвам итә. 23,30 ноябрь көннәрендә 9 сыйныф укучылары рус теле һәм математика фәннәреннән диагностик тестлаштыру,15,22 ноябрь көннәрендә мониторинг тикшеренүләре үтте. Тестлаштыру укучыларның имтиханнарга әзерлеген күрсәтер, дип көтелә. Бу исә уку елы ахырына кадәр авыррак үзләштерелгән темалар өстендә планлы эш алып барырга ярдәм итәчәк. Тестлаштыру өчен материаллар федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры китереп төзелгән.Тестлаштыру биремнәре Республиканың белем бирү сыйфатын мониторинглау (РЦМКО) үзәгеннән алынды.

Математика укытучысы Галимжанова Г.Ә.,рус теле һәм әдәбияты укытучысы Арсланова И.М. укучыларны имтиханнарга әзерләүгә көчләрен кызганмыйлар, авыррак үзләштерүче укучылар белән өстәмә шөгыльләнәләр.


Укучыларга бу җаваплы чорда тырыш һәм җаваплы булуларын , имтиханнарга әзерлекне тиешенчә алып баруларын телибез.Уңышлар сезгә!



## Олимпиада җиңүчеләре

"Инфоурок"Бөтенроссия проекты үткәргән фән олимпиадаларында мәктәбебез укучылары соңгы 3 елда бик актив катнашалар. Шушы көннәрдә олимпиадаларның нәтиҗәсе билгеле булды. Олы Кибәхуҗа башлангыч мәктәбенең 2-4 сыйныф укучылары математика, рус теле, әйләнә-тирә дөнья фәннәреннән олимпиадаларда катнашып, яхшы нәтиҗәләргә ирештеләр, 1, 2, 3 дәрәҗә дипломнарга лаек булдылар. Балаларның уңышларында укытучылары Шәяхмәтова И.Р., Мостафина К.М., Вәлиева М.А. ларның улеше зур. Укытучылар рәхмәт хатларына ия булды. Алга таба да уңышларга ирешүегезне теләп калабыз.

Менә алар, җиңүчеләр: **2 класстан Закиров Илнур-«О безопасности знаю всё»-2 урын, литературное чтение-3 урын;Муликова Динә-математика-1 урын,Набиуллин Рөстәм-окружающий мир-1урын,Хайруллин Рәсим-русский язык-1 урын;3 класс: Миннебаев Илназ-1 урын;4 класс:Шаһиева Диләра-русский язык-1 урын.**



## Минем туган ягым

Укытучыларга үзара тәҗрибә уртаклашу өчен интернет - порталлар куп. Шуларның берсе- "Альянс учителей" порталы. Укытучылар альянсы октябрь аенда "Минем туган ягым" дип исемләнгән халыкара конкурс оештырды. Конкурска укытучылар үзләренең укучыларының туган яклары турында эшләнгән иҗади эшләрен җибәрделәр. Безнең мәктәптән башлангыч сыйныфлар укытучысы Газизова Рушания Хатиповна 2 нче сыйныф укучысы Рахматуллина Диана белән катнашты. Укучының эше сертификат алды.

# БӨЕК ЖИҢҮГӘ-70 ел













## *Җиңүгә илткән юллар*

Бу уку елында халкыбызның Бөек Ватан сугышында җиңүенә 70 ел тула. Шул уңайдан мәктәбебездә бик киң масштаблы эш бара: сугыш ветераннары турында мәгълүматлар барлана, музей җитәкчесе Рахматуллина А.Ә. тарафыннан сугыш ветераннарының тол хатыннары истәлекләреннән видеоязма ясалды. "Туган якны өйрәнү" түгәрәгенә йөрүче укучылар белән музейдагы "Күңелләрдә сугыш ярасы" почмагы яңартылды.Сыйныф җитәкчеләре сыйныф сәгатьләрен "Җиңүгә илткән юллар" темасы астында алып баралар.Балалар бу якты көннәргә нинди корбаннар бәрабәренә ирешелгәнлеген аңласыннар өчен видеофильмнар күрсәтелә. Рәхмәт Сезгә, исән калганнар! Хәтердә Сез һәлак булганнар!

19 ноябрь көнне Казаклар авылы клубында Бөек Җиңүнең 70 еллыгына карата "Җиңүгә илткән юллар" дип исемләнгән иҗат фестиваленең сайлау туры булып үтте. Анда мәктәбебез коллективы әдәби- музыкаль композиция белән чыгыш ясады. Композиция сугыш чоры җырлары, укучыларның сугыш чорын сурәтләгән шигырьләре, биюләре белән үрелеп барды. Мәртәбәле жюри коллектив чыгышын югары бәяләде.

## Парламент дәресләре



Укучыларда ватанпәрвәрлек сыйфатлары тәрбияләү, хокукый белемнәрен тирәнәйтү максатыннан 22, 24 нче ноябрь көннәрендә мәктәбебездә Парламент дәресләре булып үтте. Дәресләрне "Законнар кайда туа" темасы астында, **Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 20 еллыгына** багышлап тарих укытучысы Рахматуллина А.Ә. үткәрде.Дәресләрнең дәвамы булып шушы темага үткәрелә торган рәсем , иншалар,видеороликлар конкурсы тора. Укучыларыбызны бәйгеләрдә актив катнашырга чакырабыз.



Закон бәйрәме

6 ноябрь көнне республикабыз Татарстан Конституциясе кабул ителгән көнне бәйрәм итә. Конституция – республикабызның Төп законы.Ул бүгенге республикабызның социаль-икътисади үсешенең нигезе.Төп законыбызда билгеләп үтелгәнчә,республика халкының мул тормышта яшәве җәмгыять үсешенең мөһим күрсәткече.

## Фән олимпиадаларының муниципаль туры башланды



17 ноябрь фән олимпиадаларының муниципаль туры башланып китте. 17- 22 ноябрь көннәрендә олимпиадалар безнең мәктәптә үтте.
Фән олимпиадаларында катнашучы сәләтле балаларга уңышлар телибез.

## Инглиз теленнән тестлаштыру



Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының "Татарстан Республикасы муниципаль оешмаларында 4нче сыйныф укучыларына инглиз теленнән тестлаштыру үткәрү турында"гы приказы нигезендә 29 октябрь көнне Кече Кибәхуҗа төп һәм филиал- М.Мостафин исемендәге Олы Кибәхуҗа башлангыч мәктәбенең 4нче сыйныф укучылары инглиз теленнән диагностик тестлаштыру үтте.Тестлаштыру инглиз теленнән укучыларның белем дәрәҗәсен ачыклау максатыннан үткәрелде. Шушы көннәрдә тестлаштыруның нәтиҗәләре билгеле булды.

# КОТЛЫЙБЫЗ!

18 ноябрь көнне Кече Кибәхуҗа төп мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Гарипова Гөлсинә Зөлфәровна**, 25ноябрь көнне физика-химия укытучысы, китапханәче **Нигъмәтҗанова Хәдичә Нургалиевна** туган көннәрен билгеләп үтә.

**ХӨРМӘТЛЕ УКЫТУЧЫЛАР!**

Сезне чын күңелебездән ТУГАН КӨННӘРЕГЕЗ белән тәбрик итәбез.Сезгә нык сәламәтлек, гаилә бәхете, матур киләчәк телибез.

Туган көннәр ел да кабатлана,
Ләкин кабатланмый үткәне.
Бәхет, шатлык һәм тазалык белән
Килеп торсын иде көткәне.




Кадерле укучыларыбыз
Әскарова Әдилә һәм Даутова
Дилбәр ноябрь аенда туган
көннәрен билгеләп үтә.
Туган көндә матур теләк
Булсын әле үзегезгә:
Күктән кояш балкып торсын,
Нурлар сибеп йөзегезгә.
Шаулап чәчәк атып торсын
Бакчаларда гөлләрегез,
Бүгенгедәй ямьле үтсен
Киләчәктә көннәрегез.




**Газетаны гамәлгә куючы:**
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Кече Кибәхуҗа төп мәктәбе

**Адрес:**
422080,ТР, Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авылы,Кече урам, 10 нчы йорт
**e-mail:** mkibiakozi40@mail.ru

**Редактор:Газизова Рушания Хатиповна**





# Мәдәни көндәлек

12 ноябрьдә Казаклар авыл китапханәсендә Олы Кибәхуҗа башлангыч мәктәбе укытучысы Мостафина К.М. "Татарстан.Тарихи истәлекле урыннары" темасына Бердәм мәдәни дәрес үткәрде. Дәрестә 1 сыйныф укучылары, аларның әти-әниләре, Кече Кибәхуҗа төп мәктәбенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Мөхәмәдиеа Н.Д., ветеран укытучы Нигъмәтҗанова Г.Н., китапханәче Рахматуллина А.А. катнашты. Укучылар китапханә белән таныштылар, китапханәгә язылып, китаплар алдылар. Аларга "Мәдәни көндәлек" тапшырылды. Китапханәче Рахматуллина А.А. көндәлекне тутыру тәртибе белән таныштырды.

## Бала хокуклар дөньясында



11 ноябрь көнне мәктәбебездә "Бала хокуклар дөньясында" дип исемләнгән информацион иртә үткәрелде. Мәктәпкүләм бу чараны 9 нчы сыйныф җитәкчесе Галимҗанова Г.Ә. үткәрде. Чара барышында презентация аша балаларның хокуклары аңлатылды. Укучылар Бала хокуклары турында Конвенциянең эчтәлеге белән таныштылар.Республикабызда балаларның хокукларын яклаучы оешмалар эшчәнлеге, бала хокукларын яклаучы белгеч Удачина Гүзәл Любисовна белән контактка керә алу мөмкинлекләре яктыртылды. Уен формасында дәвам иткән чара балаларга истә калырлык һәм файдалы булды.

# ӘНИЛӘР КӨНЕ



*Әни, әнкәй… Бу якты дөньяга килгәч тә безне, йомшак куллары белән сыйпап, ак биләүгә биләүче, еласак, жыр көйләп юатучы, татлы йокыдан иркәләп уятучы, яшәргә көч - дәрт бирүче, гомер буена кайгы – шатлыкларыбызны уртаклашучы, тормышыбызнын бизәге, таянычы, акыллы уй – фикерләре белән тормыш дигән олы юлдан алып баручы ул. Җәмгыятебез дә әниләрнең ижтимагый әһәмиятен күтәрү максатыннан Россия Федерациясе Президентының 1998 елнын 30 гыйнварында чыккан №120 номерлы карары нигезендэ Россиядә ноябрь аеның сонгы якшәмбесе ел саен "Әниләр көне" булып билгеләп үтелә. Быел ул 30 ноябрь көненә туры килә. Кадерле, газиз әниләребез! Сезне бәйрәмегез белән чын йөрәктән котлыйбыз. Сезгә ныклы сәламәтлек, озын гомер телибез.*




*Әни, әнием, әнкәй! Кадерләп, назлап әйтәбез, күңелебездәге бөтен рәхмәтне шушы гади сүзгә салабыз, һәрвакыт янибызда булган, уңышларыбыз өчен шатланып, кайгыларыбызны уртаклашып яшәгән газиз әниебезгә дәшәбез. Халык ана хакын хаклауны Аллаһ хакын хаклауга тиңли. Ана турындагы бер әйтемне искә алыйк: "Анаңны арка кочып Мәккәгә алып барсаң да, бурычыңны үтәп җиткерә алмассың. Анаң өчен учыңда тәбә куырсаң да, хакын хисаплап бетерә алмассың". Гасырлар аша килеп ирешкән бу гыйбрәтле, канатлы сүзләрне җаныбызга, аңыбызга сеңдерү зарур.*

*Балагызның берәве сез,*

*Гаиләнең йөрәге сез,*

*Иминлекнең терәге сез,*

*Һәркемнең кирәге сез.*

*Сез чаялар, сез батырлар,*

*Сез дөньяда иң матурлар.*

*Сез булганга тормыш ямьле,*

*Сез булганга яшәү гамьле .*



## Җитәкчеләр семинарда



20 ноябрь көнне Казан шәһәрендә Татарстан республикасы мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре өчен семинар үтте.Семинар мәгариф өлкәсендәге законнарга кергән үзгәреш шартларында идарә итүне оештыру мәсьәләләренә багышланды. Семинарда башка җитәкчеләр белән бергә мәктәбебез директоры **Әхмәтҗанова Найлә Нуретдиновна** да катнашты.



## XXI гасырда белем бирүне үзгәртеп кору дәвам итә

7 ноябрь көнне мәктәбебез укытучылары Сингапур структуралары буенча белем бирү тренингларында укуда булды.Укулар Югары Кибәхуҗа урта мәктәбендә "Фикерләү культурасын үстерү" темасы астында барды." Балалар үзләрен чолгап алган интеллектуаль тирәлек эчендә тәрбияләнә",- дип язган иде Лев Выготский. Безгә, укытучыларга, дәресләрдә укучыларны чолгап алган шундый интеллектуаль тирәлек булдырырга кирәк, монда укучылар актив фикерләү сәләтенә ия булырга,үз фикерен әйтә белү күнекмәләренә ия булырлык булсын. Тренерларыбыз Алия Рафисовна, Валентина Марсовна, Айгөл Гыйлфановналар безне шуңа өйрәтте. Трениглар бик җанлы, мавыктыргыч үтте.

